РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село
Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән
авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

18.01.2023 ел №162

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советында, Башкарма комитетында һәм башка органнарда муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында»2021 елның 22 декабрендәге 83 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советында, Башкарма комитетында һәм башка органнарда муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елның 22 декабрендәге 83 номерлы карары белән (Чирмешән муниципаль районы Советының 2022 елның 26 августындагы 132 номерлы, 2022 елның 07 сентябрендәге 137 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советында, Башкарма комитетында һәм башка органнарда муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 нче бүлектә. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль учреждениеләре» 4.3 бүлекчәсенең исемен яңа редакциядә бәян итәргә «4.3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Яшьләр һәм спорт эшләре бүлеге» муниципаль учреждениесе».

2. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советында, Башкарма комитетында һәм башка органнарда муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елның 22 декабрендәге 83 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2022 елның 7 сентябрендәге 137 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов